КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 июнь г.Казань № 518

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 июнь, 430 нчы; 2016 ел, 9 апрель, 210 нчы; 2016 ел, 21 ноябрь, 857 нче; 2017 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 19 октябрь, 797 нче; 2018 ел, 6 апрель, 211 нче; 2018 ел, 31 июль, 623 нче; 2018 ел, 3 декабрь, 1076 нчы; 2019 ел, 12 март, 178 нче; 2019 ел, 28 май, 446 нчы, 2019 ел, 12 ноябрь, 1033 нче, 2020 ел, 06 апрель, 256 нчы, 2020 ел, 22 июнь, 512 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 - 2023 елларга» сүзләрен «2014 - 2024 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2014 - 2023 елларга» сүзләрен «2014 - 2024 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа исемендә «2014 - 2023 елларга» сүзләрен «2014 - 2024 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программа исеме | «2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасы (алга таба - Программа) |
| Программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты |
| Программаның максаты | Үсеп килүче туризм инфраструктурасын, шулай ук мәдәни-тарихи, табигый потенциалны, республиканың вакыйгалар туризмы потенциалын һәм кунакчыллык индустриясен үстерү базасында Россия һәм халыкара туристлык базарларында Татарстан Республикасы туристлык комплексының конкурентлык сәләтен арттыру |
| Программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасының уңай туристик имиджын формалаштыру, халыкка күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең күләмен һәм төрлелеген арттыру.<br>2. Татарстан Республикасының туристлык-рекреацион комплексын үстерү.<br>3. Конкурентлыкка сәләтле туристик продукт булдыру һәм аны перспективалы туристлык базарларында үстерү.<br>4. Республика туристик продуктының сыйфатын, туристларга хезмәт күрсәткәндә туризм индустриясе объектларында, гамәлдәге эчке һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, кунакчыллык дәрәҗәсен арттыру.<br>5. Туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү |
| Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2024 еллар<br>I этап: 2014 – 2017еллар;<br>II этап: 2018 – 2024 еллар»; |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 5 706,6 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 367,2 млн.сум.<br>2014 ел - 20,0 млн. сум;<br>2015 ел - 97,3 млн. сум;<br>2016 ел - 87,1 млн. сум;<br>2017 ел - 231,5 млн. сум;<br>2018 ел - 99,8 млн. сум;<br>2019 ел - 120,1 млн. сум;<br>2020 ел - 125,2 млн. сум; |

| | |
|---|---|
| | 2021 ел - 207,5 млн. сум;<br>2022 ел - 188,9 млн. сум;<br>2023 ел - 94,9 млн. сум;<br>2024 ел - 94,9 млн. сум;<br>федераль бюджет акчасы - 447,9 млн. сум:<br>2017 ел - 41,8 млн. сум;<br>2020 ел - 109,5 млн. сум;<br>2021 ел - 155,6 млн. сум;<br>2022 ел - 141,0 млн. сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итүгә планлаштырылган муниципаль бюджетлар акчасы - 5,1 млн. сум:<br>2014 ел - 3,3 млн. сум;<br>2015 ел - 1,8 млн. сум;<br>билгеләнгән тәртиптә җәлеп итүгә планлаштырылган бюджеттан тыш акчалар - 3 886,4 млн. сум:<br>2015 ел - 250,0 млн. сум;<br>2016 ел - 779,2 млн. сум;<br>2017 ел - 103,1 млн. сум;<br>2020 ел - 1 354,1 млн. сум;<br>2021 ел - 1 400,0 млн.сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле финас елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Программада Татарстан Республикасы территориясендә туристлык-рекреацион һәм автотуристик кластерлар төзү күздә тотыла.<br>Программа чараларын финанслау күләмнәре кластерларның проект документациясен төзегәндә, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларына капитал салулар планында төгәлләштерелергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |
| «Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге | Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү күздә тотыла:<br>Татарстан Республикасына эчке һәм читтән килгән туристлар агымын арттыру:<br>2014 ел - 2 530,7 мең кеше;<br>2015 ел - 2 750,4 мең кеше;<br>2016 ел - 2 955,5 мең кеше;<br>2017 ел - 3 181,0 мең кеше;<br>2018 елда - 3 423,8 мең кеше;<br>2019 ел - 3 627,8 мең кеше; |

| | |
|---|---|
| күрсәткечләре | 2020 ел - 1 911,7 мең кеше;<br>2021 ел - 2 528,7 мең кеше;<br>2022 ел - 3 242,3 мең кеше;<br>2023 ел - 3 617,9 мең кеше;<br>2024 ел - 3 798,7 мең кеше;<br>халыкка күрсәтелгән түләүле туристик хезмәтләр күләме:<br>2014 ел - 10 030,2 млн.сум;<br>2015 ел - 11 310,5 млн.сум;<br>2016 ел - 11 696,3 млн.сум;<br>2017 ел - 13 566,5 млн. сум;<br>2018 ел - 14 258,4 млн.сум;<br>2019 ел - 14 500,0 млн.сум;<br>2020 ел - 9 860,5 млн.сум;<br>2021 ел - 9 727,4 млн. сум:<br>2022 ел - 12 506,6 млн. сум;<br>2023 ел - 13 896,2 млн. сум;<br>2024 ел - 14 591,1 млн. сум;<br>туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә әзерләнгән белгечләр саны:<br>2014 ел - 400 кеше;<br>2015 ел - 425 кеше;<br>2016 ел - 450 кеше;<br>2017 ел - 475 кеше;<br>2018 ел - 480 кеше;<br>2019 ел - 485 кеше;<br>2020 ел - 220 кеше;<br>2021 ел - 495 кеше;<br>2022 ел - 500 кеше;<br>2023 ел - 500 кеше;<br>2024 ел - 500 кеше»; |

Программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Максат, бурычлар, программа чаралары, Программаны гамәлгә ашыруның
көтелгән соңгы нәтиҗәләре тасвирламасы,
аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программаның максаты һәм бурычлары дөньякүләм туризмның торышын һәм үсеш тенденцияләрен югарыда үткәрелгән анализ, шулай ук Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында туризмны үстерү нигезендә формалаштырылган.

Программаның максаты - үсеп килүче туризм инфраструктурасын, шулай ук мәдәни-тарихи, табигый потенциалны, республиканың вакыйгалар туризмы потенциалын һәм кунакчыллык индустриясен үстерү базасында Россия һәм халыкара туристлык базарларында Татарстан Республикасы туристлык комплексының конкурентлык сәләтен арттыру

Программа максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Республикасының уңай туристик имиджын формалаштыру, халыкка күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең күләмен һәм төрлелеген арттыру.

2. Татарстан Республикасының туристлык-рекреацион комплексын үстерү.

3. Конкурентлыкка сәләтле туристик продукт булдыру һәм аны перспективалы туристлык базарларында үстерү.

4. Республика туристик продуктының сыйфатын, туристларга хезмәт күрсәткәндә туризм индустриясе объектларында, гамәлдәге эчке һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, кунакчыллык дәрәҗәсен арттыру.

5. Туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү.

Республиканың уңайлы туристик имиджын булдыру, халыкка күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең күләмен һәм төрлелеген арттыру бурычын хәл итү Россия Федерациясе территориясендә уздырыла торган махсус туристик күргәзмәләрдә катнашуны, шулай ук Татарстан Республикасында перспектив туристик проектларны, программаларны һәм маршрутларны билгеләүгә юнәлдерелгән республика конкурсларын оештыруны күздә тота.

Татарстан Республикасының туристлык-рекреация комплексын үстерү бурычын хәл итү кайбер перспектив туристик кластерлар проектларын булдыру эшләрен аерым төбәкләрнең бизнес-ширкәтләрен дәүләти-хосусый партнерлык формалаштыру процессларына җәлеп итү исәбенә башкаруны күздә тота. Шул ук вакытта туристик һәм туристлык-рекреацион кластерлар инфраструктурасын комплекслы үстерү планлаштырыла, алар регион үсеше, регионара элемтәләр нокталары булачак, үз тирәсендә кече һәм урта бизнесны үстерүне активлаштырачак. Күрсәтелгән челтәрнең элементларын аеруча популяр маршрутларда, шулай ук туристлар өчен кызыклы булган урыннар: тарихи һәм мәдәни үзәкләр, күрсәтү объектлары, туристлар өчен кызыклы башка урыннар тирәсендә урнаштыру планлаштырыла.

Программаның структур функциональ элементлары булып «Казан», «Борынгы Болгар шәһәре», «Зөя утрау-шәһәрлеге», «Алабуга яры», «Зөя-Лэнд», «Волжская Булгария» туристлык-рекреацион кластерлары тора, алар кысаларында регионның аерым территорияләрендә эчке һәм тышкы туристлык ташкыннарының интенсив үсешен тәэмин итә торган туристлык инфраструктурасын тизләтелгән үстерү, шулай ук икътисадның тиешле хезмәт күрсәтүләре өлкәсен һәм катнаш тармакларын үстерүгә мультипликатив эффект күрсәтүче шартлар булдырылачак.

Туристлык-рекреацион кластерлардан тыш, федераль трассалар янында урнашачак автотуристик кластерларны проектлау һәм булдыру каралган.

Әлеге бурычны хәл итү өчен бюджет акчаларын һәм инвесторлар акчаларын уртак финанслау мөмкинлекләреннән файдалану күздә тотыла. Бюджет акчалары, шул исәптән «Россия Федерациясендә эчке һәм тышкы туризмны үстерү (2011 - 2018 еллар)» федераль максатчан программаны һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 316 номерлы карары белән расланган «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Туризм» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру этабында Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет акчаларын өстенлекле кластерларның инженерлык инфраструктурасы объектларын финанслауга, ә инвесторлар акчаларын туристлык-

рекреация билгеләнешендәге объектларны финанслауга кертү планлаштырыла.

Туристлык инфраструктурасын үстерү һәм заманча комплекслар булдыру, реставрацияләнгән тарихи-мәдәни мирас объектларын әйләнешкә кертү белән беррәттән, төрле юнәлештәге яңа туристик маршрутлар эшләү өчен шартлар тудырачак. Бу төрле категориядәге туристларның кулланучылар ихтыяҗын канәгатьләндерергә, туристлык объектларының күпкырлы эшләвен һәм туристлар агымының тотрыклы үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Конкурентлыкка сәләтле туристик продукт булдыру һәм аны эчке һәм халыкара базарларда үстерү бурычын хәл итү туристлык-рекреация комплексын үстерү буенча алдагы бурычның логик дәвамы булып тора һәм Татарстан Республикасының туристик брендын булдыруны, танылган брендларның («Борынгы Болгар шәһәре», «Свияжск утрау-шәһәре», «Алабуга» һәм башкаларның) конкурентлыкка сәләтлелеген үстерүне һәм арттыруны, шулай ук республика турпродукты ассортиментын киңәйтү һәм туризмның перспективалы юнәлешләре буенча яңа брендлар (этник, мәдәни-танып белү, экологик, балыкчылык, авыл туризмын, сәламәтләндерү, ял итү һәм рекреациянең актив ысуллары белән) булдыру күздә тота. Моннан тыш, социаль әһәмиятле проектларга һәм туризм өлкәсендәге инициативаларга дәүләт ярдәме планлаштырыла.

Дөньякүләм һәм эчке туристлык базарларында Татарстан Республикасының туристик продуктын алга чыгару өчен, Программаны гамәлгә ашыруның бөтен срогы дәвамында беренче чиратта «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының туристик мөмкинлекләре булуны шактый арттырырга, заманча IT-сервислар, туризм өлкәсендә проектлар һәм хезмәтләр эшләүне һәм алардан файдалануны оештырырга, мәгълүмат-пропаганда кампанияләрен җәелдерүне һәм Татарстан Республикасының туристлык имиджын туристлар өчен җәлеп итүчән юнәлеш буларак булдыруга һәм алга җибәрүгә юнәлдерелгән башка чаралар комплексын уздыруны тәэмин итәргә кирәк. Программа чараларында шулай ук туристлык бизнесы субъектлары турпродуктны алга җибәрүгә керткән акчалар исәпкә алынырга мөмкин.

Республика туристик продуктының сыйфатын күтәрү һәм туристларга хезмәт күрсәтү бурычын хәл итү өчен, гамәлдәге эчке һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, республиканың туристик потенциалын, туристик продуктның сыйфатын һәм конкуренциягә сәләтлелеген бәяләүгә, шулай ук күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең сыйфатын мониторинглауга, тармакны технологик яктан тәэмин итүне камилләштерүгә, заманча туризм статистикасын формалаштыруга бәйле кайбер чараларны гамәлгә ашыру планлаштырыла. Әлеге юнәлеш туризм өлкәсендә кадрлар әзерләү системасын үстерүне, шул исәптән югары һәм урта һөнәри белем бирүне, кадрларның квалификациясен күтәрүне һәм яңадан әзерләүне, туристлык продуктының сыйфаты белән идарә итү өлкәсендә туризм һәм кунакчыллык өлкәсе иҗтимагый һөнәри оешмалары белән хезмәттәшлекне оештыруны күздә тота. Моннан тыш, әлеге бүлеккә туристлык навигациясенең заманча системасын булдыру буенча чаралар кертелгән, шул исәптән халыкара туризмда кабул ителгән күрән туристик күрсәткечләр урнаштыру буенча туристлык объектларына юнәлеш буенча төп трассаларда.

Әлеге чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә эчке һәм халыкара туристлык

базарларында туристлык продуктының конкурентлыкка сәләтлелеген, күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең сыйфатын арттыру өчен шартлар булдырылачак.

Туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү бурычын хәл итү туризмның өстенлекле төрләрен үстерүне, туризм, туристлык индустриясе һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары белән хезмәттәшлекне, туристлык базарында катнашучылар белән хезмәттәшлекне, туризм өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруда юридик һәм физик затларга дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыруны күздә тота.

Республиканың уңай туристик имиджын формалаштыру, халыкка күрсәтелә торган туристлык хезмәтләренең күләмен һәм төрлелеген арттыру бурычларын хәл итү беренче чираттагы чараларга дәүләт ярдәме белән билгеләнә:

Россия туристик күргәзмәләрендә катнашу һәм уздыруны оештыру;

туристлык индустриясен үстерүгә юнәлдерелгән конкурслар оештыру һәм уздыру;

конференцияләр һәм семинарларда катнашу һәм уздыруны оештыру.

Татарстан Республикасының туристлык-рекреацион комплексын үстерү эше түбәндәге чаралар кысаларында алып барылачак:

республика туризмы инфраструктурасын үстерүнең инвестиция тәкъдимнәренең һәм проектларының база пакетын булдыру;

өстенлекле туристлык-рекреацион кластерларның һәм туристлык үзәкләренең тәэмин итүче инфраструктура объектларын капиталь төзү һәм модернизацияләү
“Казан”, “Борынгы Болгар шәһәре”, “Зөя утрау-шәһәрлеге”, “Алабуга ярлары”, “Зөя-Лэнд”, “Идел Болгары”;

автотуристик кластерларны проектлау һәм булдыру.

Конкурентлыкка сәләтле туристик продукт булдыру һәм аны эчке һәм халыкара базарларда үстерү чаралары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Татарстан Республикасының туристик брендын булдыру;

республика туристик брендларының (Казан шәһәре, Алабуга шәһәре, Чистай шәһәре һәм Чистай муниципаль районы, Яшел Үзән шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы, «Борынгы Болгар шәһәре», «Зөя утрау-каласы», «Кыш бабай һәм Кар кызы резинциясе») үсешен һәм конкурентлыкка сәләтлелеген арттыру;

республика турпродукты ассортиментын киңәйтү, туризмның перспективалы юнәлешләре (этник, мәдәни-танып белү, экологик, балыкчылык, авыл, сәламәтләндерү, ял итү һәм рекреация, хәрәкәтләнүнең актив ысуллары булган туризмны булдыру), шулай ук социаль әһәмиятле проектларга һәм инициативаларга дәүләт ярдәме күрсәтү, республика вакыйгалар календарен булдыру.

Татарстан Республикасының туристлык продуктын алга җибәрү чаралары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының туристлык мөмкинлекләре булуны, туризм буенча республика сайтын, шулай ук конкурентлыкка сәләтле цифрлы контентны, сервисларны хуплауны һәм алга җибәрүне кертеп, арту һәм мәгълүмат ресурсларын тутыру;

туристлык мәгълүмат үзәкләре (Call-centrены да кертеп) эшчәнлеген үстерү һәм аларның эшен, Россия һәм чит ил туристлык мәгълүмат үзәкләре белән үзара

хезмәттәшлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасында туризм турында реклама-имидж материаллары бастырып чыгару һәм тарату;

туристлык имиджын формалаштыруга һәм республиканы туристлык базарларында күрсәтүгә юнәлдерелгән халыкара, гомумроссия, төбәкара, республика чараларын оештыруга һәм уздыруга, шул исәптән реклама фильмнары һәм роликлар, цикллы телетапшырулар булдыруга, күчмә презентацияләрдә (roadshow) катнашуга, республикада Россия һәм чит ил төбәкләре вәкилләре катнашында халыкара очрашулар оештыруга һәм уздыруга, башка имидж чараларын уздыруга (шул исәптән «Бөек Идел» проекты һәм башка регионара чаралар, Казан - Зөя, Болгар һәм башка маршрутлар буенча ел саен уздырыла торган авто- һәм велопробеглар кысасында) үткәрүгә юнәлтелгән.

Гамәлдәге эчке һәм халыкара стандартларны исәпкә алып, республика туристик продуктының сыйфатын яхшырту һәм туристларга хезмәт күрсәтү чаралары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

туристлык базарының туристлык потенциалын, туристлык продуктының сыйфатын һәм конкурентлык сәләтен өйрәнүгә һәм бәяләүгә, шулай ук күрсәтелгән туристлык хезмәтләренең сыйфатын мониторинглауга бәйле махсус тикшеренүләр уздыру;

туристлык индустриясе кадрларының халыкара вакыйгаларга квалификациясен күтәрүне оештыру;

туризм һәм кунакчыллык индустриясе өлкәсендә кадрлар әзерләү системасын үстерү;

туристлык индустриясе өлкәсендә коммерциячел булмаган һәм иҗтимагый оешмаларның нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

туризмның заманча статистикасы системасын булдыру, мәгълүматны җыюны һәм анализлауны оештыру;

туристик навигациянең заманча системасын булдыру.

Туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү бурычын хәл итү туризм өлкәсен үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен һәм стратегиясен билгеләүне һәм аларны гамәлгә ашыруны күздә тота.

Программаны тормышка ашыру сроклары: 2014 – 2024 еллар. Программа ике этапта тормышка ашырылачак. Беренче этап - 2014 - 2017 еллар, икенче этап - 2018 - 2024 еллар. Погramманың төп максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, шулай ук программа чаралары киселешендә финанслау күләмнәре Программага 1 нче кушымтада күрсәтелгән.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 5 706,6 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 367,2 млн.сум.

2014 ел - 20,0 млн. сум;

2015 ел - 97,3 млн. сум;

2016 ел - 87,1 млн. сум;
2017 ел - 231,5 млн. сум;
2018 ел - 99,8 млн. сум;
2019 ел - 120,1 млн. сум;
2020 ел - 125,2 млн. сум;
2021 ел - 207,5 млн. сум;
2022 ел - 188,9 млн. сум;
2023 ел - 94,9 млн. сум;
2024 ел - 94,9 млн. сум;
федераль бюджет акчасы - 447,9 млн. сум:
2017 ел - 41,8 млн. сум;
2020 ел - 109,5 млн. сум;
2021 ел - 155,6 млн. сум;
2022 ел - 141,0 млн. сум;
билгеләнгән тәртиптә җәлеп итүгә планлаштырылган муниципаль бюджетлар акчасы - 5,1 млн. сум:
2014 ел - 3,3 млн. сум;
2015 ел - 1,8 млн. сум;
билгеләнгән тәртиптә җәлеп итүгә планлаштырылган бюджеттан тыш акчалар - 3 886,4 млн. сум:
2015 ел - 250,0 млн. сум;
2016 ел - 779,2 млн. сум;
2017 ел - 103,1 млн. сум;
2020 ел - 1354,1 млн. сум;
2021 ел - 1400,0 млн. сум.»;
Программаның V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыру 2024 ел ахырына Татарстан Республикасы туристлык базарының конкурентлык сәләтен арттырырга, шулай ук Россия һәм чит ил гражданнарының сыйфатлы туристлык хезмәтләренә ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлек бирәчәк.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасының туристлык-рекреацион комплексы сизелерлек үсеш алачак, туристлык хезмәтләренең сыйфаты күтәреләчәк, шулай ук дөнья һәм эчке базарларда туристлык продуктын алга җибәрү бурычы хәл ителәчәк.

Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2024 елда эчке һәм читтән керү туристик агымнары күләме 3 798,7 мең кеше тәшкил итәр дип көтелә; туризм өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру күләме - 1 4591,1 млн.сум; Программаның гамәлдә булган чорында туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә әзерләнгән белгечләр саны - 500 кеше.

Программаны гамәлгә ашыру чорында Татарстан Республикасының туризм һәм авыл яны өлкәсендә эш урыннары үсеше якынча 20 мең кеше тәшкил итәчәк.

Программада каралган чаралар Татарстан Республикасында туризмны үстерүдә уңай тенденцияләрне ныгытырга мөмкинлек бирәчәк, бу гамәлдәге туристик

инфраструктураны яңартуга һәм, нәтиҗә буларак, Татарстан Республикасы территориясендә заманча конкурентлыкка сәләтле туристик тармак булдыруга китерәчәк. Беренчел бәяләүләр буенча, Программаны гамәлгә ашыру, күрсәтелгән чараларны үтәүне исәпкә алып, аның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң, югары нәтиҗәле туристик-рекреацион инфраструктура төзергә мөмкинлек бирәчәк, бу «Туризм» статьясы буенча Татарстан Республикасы бюджетының керем өлеше үсешенең алга таба да югары динамикасын тәэмин итәчәк.

Программаның күрсәтелгән бурычларын хәл итү республика һәм тулаем Россия Федерациясе икътисадының тотрыклы үсеше өчен мультипликатив нәтиҗә бирәчәк, әмма бу бурычлар дәүләт һәм муниципаль берәмлекләр кооперациясе һәм проект нигезендә хосусый инвесторлар кооперациясе ярдәмендә генә гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

Программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин